Чүпрәле муниципаль районы
Советы

КАРАР

2018 елның 30 марты № 26/5

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының
югары һәм төп төркемнәренә караган
вакантлы идарә вазыйфаларын һәм вазыйфаларын
биләүгә кадрлар резервы турындагы нигезләмәнең
29 пунктына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Чүпрәле муниципаль районы уставы, Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә, Чүпрәле муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервын формалаштыру буенча үзара хезмәттәшлекне оештыру турында төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Чүпрәле муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы идарәче вазыйфаларны һәм вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турында» 2014 елның 9 апрелендәге 40/3 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм төп төркемнәренә караган вакантлы идарә вазыйфаларын һәм вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервы турында нигезләмәнең 29 пунктына, «ике дәгъвачы» сүзләрен «ике дәгъвачыдан кимендә ике дәгъвачы җыйган» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы урынбасары,
Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Советы Рәисе урынбасары: А.И. Сарафанов